| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

05.11.2014 Казан ш. № 2401-р

**Татарстан Республикасының Алексеевск, Спас (өлешчә), Чистай (өлешчә) муниципаль районнары территориясендә газ бүлгеч челтәрләрнең саклау зонасы чикләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау турында карарлар кабул итү тәртибен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында» 30.04.2014 № 288 карарына туры китереп, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Земля» республика кадастр үзәге» ААҖ (алга таба – «Земля» РКҮ ААҖ) башкарган документациягә туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклык зонасы чикләрен расларга:

1.1. Алексеевск муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, 673,546 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 2,741237 кв.км.лы (2 741 237 кв.м) территорияне тәшкил иткән, әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Чистопольгаз» газ бүлгеч газүткәргечен 2014 елның 5 августыннан 2014 елның 10 сентябре аралыгында «Земля» РКҮ ААҖ башкарган һәм 2014 елның 10 октябрендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән

килештерелгән җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зонасы картасындагы (план) мәгълүматлар нигезендә;

1.2. Спас муниципаль районы (өлешчә) территориясендә урнаштырылган, 2,829 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 11 340 кв.м территорияне тәшкил иткән, әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Чистопольгаз» газ бүлгеч газүткәргечен 2014 елның 5 августыннан 2014 елның 10 сентябре аралыгында «Земля» РКҮ ААҖ башкарган һәм 2014 елның 10 октябрендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зонасы картасындагы (план) мәгълүматлар нигезендә;

1.3. Чистай муниципаль районы (өлешчә) территориясендә урнаштырылган, 5,420 км озынлыктагы, гомуми мәйданы 21685 кв.м.лы территорияне тәшкил иткән, әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Чистопольгаз» газ бүлгеч газүткәргечен 2014 елның 5 августыннан 2014 елның 10 сентябре аралыгында «Земля» РКҮ ААҖ башкарган һәм 2014 елның 10 октябрендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән җир өсте һәм җир асты объектларының саклау зонасы картасындагы (план) мәгълүматлар нигезендә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләре объектының саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖга тәкъдим итәргә:

1) газ бүлгеч челтәрләрнең саклау зоналары турында белешмәне Күчемсез милек дәүләт кадастрына кертү чараларын күрергә;

2) әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналарына кергән әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә йөкләүләрне Күчемсез милек хокуклары һәм аның белән алыш-биреш итү бердәм дәүләт реестрында регистрацияләү чараларын күрергә;

3) әлеге карар кабул ителүгә 10 көн эчендә аны Татарстан Республикасы буенча «Росреестр федераль кадастр палатасы» филиалына юлларга, шулай ук, әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары җир төзелеше объектлары карталарын (план) XML-схемалар кулланып төзелгән һәм бирелгән мәгълүматның укылышын һәм контролен тәэмин итүче XML форматындагы файллар рәвешендә, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары турында һәм әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә булган чикләүләрне Күчемсез

милек бердәм дәүләт реестрына кертү өчен хокукларны регистрацияләү органына юлларга.

4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны җир ресурслары идарәсе башлыгы Г.Э.Миндубаевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**